РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Кукмара ш.

21.12.2021 № 753

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында һәм «Мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 22 июнендәге 422 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карарының кайбер мәсьәләләрен куллану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, исәпкә кую һәм аларны кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасын раслау турында» 2021 елның 6 ноябрендәге под-1417/21 номерлы боерыгы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гариза бирү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Административ регламент) әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. «Мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 22 июнендәге 422 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карарының (алга таба – 422 номерлы карар) 1 пунктындагы икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга. 422 нче карар Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында 422 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең

административ регламентына бәйле өлешендә кулланылмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына:

- Административ регламент текстын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзләренең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтларында урнаштырырга;

- Административ регламентны үтәү буенча чаралар күрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы И.И. Әхмәдуллинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21.12.2021 ел 753 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: Россия Федерациясе гражданнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче, 2 айдан 7 яшькә кадәрге балаларның ата-аналары (башка законлы вәкилләре) булган чит ил гражданнары (алга таба – гариза бирүчеләр).

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (алга таба – оешмалар) **чираттан тыш урнашу хокукына** түбәндәгеләр ия:

судьялар балалары;

прокурорларның һәм Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнар балалары[1]; Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга тиңләштерелгән гражданнар балалары[2];

«Террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашучы һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм федераль башкарма хакимият органнары

---

[1] Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган һәм оешмада чираттан тыш урнаштыру хокукына ия булган гражданнарның конкрет категориясе «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә билгеләнә.

[2] Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга тиңләштерелгән гражданнар Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә, аерым алганда, «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 декабрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законының гамәлдә булуын аеруча куркыныч янаган төркемнәрдәге гражданнарга тарату хакында» Россия Федерациясе Югары Советының 27.12.1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы карары нигезендә билгеләнә. Шул ук вакытта Оешмага чираттан тыш урнашуга хокук, әгәр мондый хокук Россия Федерациясе законнарында каралган булса бирелә.

хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 09 февралендәге 65 номерлы карарының 1 пунктында күрсәтелгән һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалидка әйләнгән хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәткәрләр балалары;

Дагыстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә инвалид булган хәрби хезмәткәрләр һәм эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы хезмәткәрләренең балалары.

**Оешмага беренче чиратта урнашу хокукына түбәндәгеләр ия:**

инвалид балалар һәм аларның ата-анасының берсе инвалид булган балалар;

күп балалы гаилә балалары;

«Полиция турында» 2011 елның 07 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән балалар;

«Полиция турында» 2011 елның 07 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясындагы 2 өлеше нигезендә полиция хезмәткәрләре булмаган эчке эшләр хезмәткәрләренең балалары;

«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 6 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән балалар;

«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 5 пунктының сигезенче абзацы нигезендә хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзалары балалары;

«Кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләре һәм Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 14 өлешендә күрсәтелгән балалар.

Бала бертуган (полнородные) һәм төрле әти яки әнидән булган (неполнородные) ир һәм (яки) кыз туганнары белем ала торган Оешмага укырга **өстенлекле кабул итү хокукына** ия.[1]

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында хәбәр итү:

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгечә урнаштырыла:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе биналарында (алга таба – Мәгариф идарәсе) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында гражданнар белән эшләү өчен урнаштырылган муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендларда;

Мәгариф Идарәсенең рәсми сайтында: http://edu.tatar.ru/kukmor/otdel.;

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https:/www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында

---

[1] «Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 3.1 өлеше.

(http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы);

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультацияләр түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

Мәгариф идарәсендә:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ форматында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша;

Бердәм порталның, Республика порталының интерактив формасында.

телдән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә – шәхсән яисә телефон аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат Республика реестрындагы белешмәләр нигезендә гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматтан файдалану гариза бирүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән программа тәэминатының хокук иясе белән гариза бирүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән түләү алуны, аны теркәү яки авторизацияләүне, яки аларга шәхси мәгълүматлар бирүне күздә тота торган лицензия яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча, гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Гариза бирүче шәхсән яисә телефон аша мөрәҗәгать иткәндә, килгән мөрәҗәгать нигезендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, Мәгариф идарәсе (адресы, эш графигы; белешмә өчен телефоны) урнашкан урын турында; муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында; гариза бирү ысуллары һәм сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында; муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында; рәсми сайтта муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат урнаштырылган урын турында; Мәгариф идарәсе вазыйфаи затларының гамәлләренә яисә гамәл кылмауларына карата шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелергә мөмкин.

Язма мөрәҗәгать буенча Мәгариф идарәсененңмуниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлары язма рәвештә гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм әлеге Регламентның шушы пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне җентекләп аңлаталар һәм гаризаны теркәгән көннән алып өч эш көне эчендә Гариза бирүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар гаризада мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре файдаланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Мәгариф идарәсенең рәсми сайтында һәм Мәгариф идарәсе биналарындагы гариза бирүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы муниципаль хезмәт турындагы, Мәгариф идарәсенең урнашкан урыны, белешмә өчен телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп), Мәгариф идарәсенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырыла.

Гамәлдәге редакциядә Регламент тексты Мәгариф идарәсенең рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Республика реестрында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең территориаль яктан аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән мәгълүматларның (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе), алар нигезендә мәгълүматлар кертелгән документлардагы мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуңа охшаган хата);

ЕСИА – Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы.

Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның (мөрәҗәгать итүче гражданнар һәм башкарма хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары) дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган санкцияләнгән файдалануны тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ – «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

АИС ЭДС – «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (АИС ЭДС).

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 3 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату аңлашыла.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү

2.2. Җирле үзидарәнең турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган башкарма-оештыру органы исеме

Муниципаль хезмәт Мәгариф идарәсе һәм Регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән оешмалар тарафыннан күрсәтелә.

Мәгариф идарәсенең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Эшчеләр тыкрыгы ур., 7 йорт.

Мәгариф идарәсенең эш графигы: биш көнлек, ике ял көне белән (шимбә һәм якшәмбе);

Гариза бирүчеләрне кабул итү графигы: эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр; төшке аш вакыты: 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

Мәгариф идарәсенең белешмә өчен телефоннары: 8(84364) 2-70-41, 8(84364) 2-70-68.

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Мәгариф Идарәсенең рәсми сайты адресы: http://edu.tatar.ru/kukmor/otdel.

Оешмаларның урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, рәсми сайтларының адреслары турында мәгълүмат Регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

КФҮнең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган мәгълүматны һәм соратып алудан баш тарту турында Карар кабул итү мөмкинлеге юк.

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре:

гаризаны кабул итү һәм исәпкә кую өлешендә – гаризага «теркәлгән» статусын бирү;

балаларны Оешмага кабул итү өлешендә – заявкага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителгән» статусын бирү.

2.3.2. Гариза бирүчегә кәгазьдә һәм (яки) электрон формада Бердәм портал, Республика порталы аша түбәндәге мәгълүмат бирелә:

1) юллама һәм кабул итү өчен гаризалар турында (индивидуаль номер һәм гариза бирү датасы);

2) гаризаларны эшкәртү статуслары, аларны үзгәртү нигезләре һәм аларга комментарийлар турында;

3) Оешмада урын бирү эзлеклелеге турында;

4) Оешмада урын бирү турында документ хакында;

5) баланы Оешмага кабул итү турындагы документ хакында.

2.3.3. Гариза бирүченең теләге буенча мәгълүмат Мәгариф идарәсе тарафыннан бирелгән электрон формадагы мәгълүматның эчтәлеген раслый торган кәгазь документ формасында КФҮдә тапшырылырга мөмкин.

## 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, Россия Федерациясе законнарында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, аны туктатып тору вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документларны тапшыру (җибәрү) вакыты

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

гаризаны кабул итү өлешендә – гариза кергән көннән алып 1 эш көне эчендә;

исәпкә кую өлешендә – гариза кергән көннән алып 5 эш көне эчендә;

балаларны Оешмага кабул итү өлешендә –гариза бирүче белән Оешма арасында шартнамә төзелгәннән соң 1 эш көне эчендә.

Оешмага юлламаны көтү срогы муниципаль хезмәт күрсәтү вакытына керми.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризага тиешле статус бирелгән көнне Бердәм порталда, Республика порталында Гариза бирүченең шәхси кабинетына электрон рәвештә җибәрелә.

2.4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору гамәлдәге законнарда каралмаган.

## 2.5. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәтне, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен, баланың ата-аналары (законлы вәкилләр) түбәндәге документларын тапшыралар:

- баланың атасының яисә анасының (законлы вәкиленең) шәхесен раслаучы документ йә «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә чит ил гражданының яисә гражданлыгы булмаган затның Россия Федерациясендә шәхесен раслаучы документ;

- гариза:

кәгазьдә документ формасында (Регламентка 3 нче кушымта);

«Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп

имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны интерактив формага кертү юлы белән тутырыла) Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

- психологик-медик-педагогик комиссия документы (кирәк булганда);

- сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемдә белем алу ихтыяҗын раслый торган документ (кирәк булганда);

- ооешмага беренче чиратта, чираттан тыш урнашуга хокук булуны раслый торган документлар (белешмәләр) (Регламентның 2.6. пунктының 2.6.1 пунктчасындагы тугызынчы һәм унынчы абзацларында күрсәтелмәгән гражданнар категорияләре өчен).

Исәпкә куелганда, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) үз инициативасы буенча түбәндәге документларны күрсәтергә хокуклы

гражданнарның аерым категорияләренә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүнең махсус чараларына (гарантияләр) хокукын раслаучы документлар (белешмәләр) (Регламентның 2.6 пунктының 2.6.1 пунктчасындагы тугызынчы һәм унынчы абзацларында күрсәтелгән гражданнар категорияләре өчен);

опека билгеләүне раслый торган документ (кирәк булганда),

Россия Федерациясе территориясендә бирелгән баланың туу турында таныклыгы;

беркетелгән территориядә яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык;

баланың тору урыны, фактта яшәү урыны турында белешмәләрне үз эченә алган документ (беркетелгән территориядә яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык булмаганда).

Чит ил гражданнары яки гражданлыгы булмаган затлар булган баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) баланың шәхесен таныклый торган һәм бала хокукларын бирүнең законлылыгын раслый торган документ(-лар)ны, шулай ук гариза бирүченең Россия Федерациясендә булырга хокукын раслый торган документны өстәмә рәвештә тапшыралар. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны рус телендә яисә таныкланган рус теленә тәрҗемә белән бергә тапшыралар.

Кабул итү өчен, баланың ата-анасы (законлы вәкилләр) Оешмага түбәндәгеләрне бирергә хокуклы:

баланың туу турында таныклыгын (Россия Федерациясе гражданнары булган ата-аналар (законлы вәкилләр) өчен);

баланы яшәү урыны буенча яисә беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында таныклык. Билгеләнгән территориядә яшәү урыны яки тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык булмаганда, ата-ана (законлы вәкил) баланың тору урыны, фактта яшәү урыны турында белешмәне үз эченә алган документ тапшыра;

медицина бәяләмәсе[1].

---

[1] 2022 елның 1 мартыннан медицина бәяләмәсе таләп ителми. Нигез: Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укуга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы һәм «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 сентябрендәге 471 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыкларына

2.5.2. Гаризаның электрон формасы Мәгариф Идарәсенең рәсми сайтында урнаштырылган.

Баланы исәпкә алу һәм (яки) кабул итү гаризасында ата-ана (законлы вәкилләр) тарафыннан түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

баланың туган көне;

бала туу турында таныклык реквизитлары;

Баланың яшәү урыны (тору урыны, фактта яшәү урыны);

баланың ата-анасының (законлы вәкилләрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

- баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ реквизвитлары;

опека билгеләүне раслый торган документ реквизитлары (булганда);

баланың ата-анасының (законлы вәкилләре) электрон почта адресы, телефон номеры (булган очракта);

белем бирү телен, Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне, шул исәптән рус телен туган тел буларак сайлау турында;

баланың мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган белем бирү программасы буенча укытуга һәм (яисә) инвалидны (булган очракта) индивидуаль реабилитацияләү программасы нигезендә инвалид баланы укыту һәм тәрбияләүне оештыру өчен махсус шартлар тудыруга ихтыяҗ турында;

Мәктәпкәчә төркемнең юнәлеше турында;

балага кирәкле режим турында;

белем алуга кабул итүнең теләгән датасы турында.

Исәпкә кую өчен гаризада өстәмә рәвештә кабул итү өчен сайланган Оешмалар турында белешмәләр һәм гражданнарның аерым категорияләренә һәм аларның гаиләләренә (кирәк булганда) махсус ярдәм чаралары (гарантияләр) хокукына ия булу турында баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан белешмәләр күрсәтелә.

Баланы кабул итү өчен ата-анасы (законлы вәкиле) сайлаган Оешмада укучы бертуган яисә ата-аналары төрле булган абый-энеле һәм (яисә) апа-сеңелле балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) исәпкә кую өчен гаризада өстәмә рәвештә абыйсы-энесенең (-ләренең) һәм (яисә) апа-сеңлесенең (-ләренең) фамилиясен (фамилияләрен), исемен (исемнәрен), атасының исемен (соңгысы – булган очракта) күрсәтәләр.

2.5.3. Исәпкә алу өчен гариза Мәгариф идарәсенә кәгазьдә һәм (яки) электрон формада Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырыла.

Гариза һәм кушып бирелә торган документлар КФҮ аша 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) кәгазьдә һәм электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин.

КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гаризалар һәм документлар КФҮ һәм җирле үзидарә органнары арасында тиешле килешү булганда кабул ителә.

---

үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 04 октябрендәге 686 номерлы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2021 елның 11 ноябрендә 65757 номеры белән теркәлгән).

Кабул итү турында гариза муниципаль хезмәтне гамәлгә ашыру кысаларында АИС ЭДС аша юллама алган Оешмага кәгазьдә һәм (яки) электрон формада Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырыла.

2.5.4. Гариза һәм кирәкле документлар җибәргәндә, гариза бирүче гаризага гади электрон имза белән кул куя.

Гади электрон имза алу өчен, гариза бирүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алу язмасын стандарт дәрәҗәсеннән дә ким булмаган дәрәҗәгә кадәр раслaрга кирәк.

2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар аның карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелә торган гаризага Гариза бирүче керткән белешмәләр (баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туу датасы, туу турында таныклык реквизитлары буенча идентификациясе) Граждан хәле актларын рәсмиләштерү органнары (алга таба – ГХАТ органнары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында автомат режимда расланa.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) алына:

Россия Федерациясе территориясендә бирелгән баланың туу турында таныклыгы (ГХАТ органнары тарафыннан бирелә);

чит илдә туган балаларга карата гражданлык хәлен теркәү актларының башкарылган язмалары турында белешмәләр (ГХАТ органнары тарафыннан бирелә);

опека билгеләүне раслый торган документ (опека органнары тарафыннан бирелә);

баланы яшәү урыны буенча яисә беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында таныклык (РФ эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары тарафыннан бирелә).

баланы Оешмага кабул итү өчен билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе (территориаль сәламәтлек саклау органнары тарафыннан бирелә);

түбәндәге категория гражданнарның Оешмага беренче чиратта, чираттан тыш урнашуга хокукы булуын раслый торган документлар (белешмәләр):

күп балалы гаилә балалары, Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнар балалары, инвалид балалар, ата-анасының берсе генә булса да инвалид булган гаиләләр (социаль яклау территориаль органнары тарафыннан бирелә);

судьяларның балалары, прокурорларның һәм Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары, полиция хезмәткәренең балалары (хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан

бирелә).

2.6.2. Гариза бирүче гариза биргәндә 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) электрон формада яисә мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныкланган электрон документлар формасында тапшырырга хокуклы.

## 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

гариза бирүче тарафыннан мәҗбүри тапшырылырга тиешле, Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән тулы булмаган документлар комплекты тапшыру;

аларның эчтәлеген бертөрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәле, әйтелмәгән төзәтмәләр, җитди бозулар булган документлар тапшыру;

гариза бирүче исеменнән аңа вәкаләте булмаган затның гариза (сорату) тапшыруы;

гариза бирүченең муниципаль хезмәт өчен гариза бирүчегә кирәкле муниципаль хезмәт күрсәтми торган җирле үзидарә органына, җирле үзидарә органына караган оешмага мөрәҗәгать итүе;

Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап гариза бирүе;

интерактив соратып алу формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау;

электрон формадагы гариза (сорату) һәм башка документлар гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган;

электрон документлар аларны бирү форматларына куелган таләпләргә туры килми һәм (яисә) укылмыйлар.

2.7.2. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы.

2.7.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчене кабул иткәндә дә, шулай ук Мәгариф идарәсенең җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алганнан соң да, гаризаны теркәгән көннән алып кимендә 6 эш көнендә кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 4 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Мәгариф идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетына һәм (яисә) КФҮгә җибәрелә.

2.7.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары

һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

### 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

- Оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшеннән баланың яше арту;
- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 6 нчы кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Мәгариф идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетына, КФҮгә җибәрелә.

2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылганмуниципаль хезмәт күрсәтүнең сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре.

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләргә (исәпкә алу өлешендә) Гариза бирүченең баласына карата анның нәтиҗәләре буенча медицина бәяләмәсе бирелә торган медицина хезмәте керә.[1]

### 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәт

[1] 2.10 пункты 2022 елның 1 мартына кадәр гамәлдә. Нигез: Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укуга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы һәм «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 сентябрендәге 471 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыкларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 04 октябрендәге 686 номерлы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2021 елның 11 ноябрендә 65757 номеры белән теркәлгән).

күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүмат

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларында каралмаган.

2.12. Муниципаль хезмәттән, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәттән файдалану турында гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

2.12.1. Муниципаль хезмәттән файдалануга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт турында соратуын, шул исәптән электрон рәвештә теркәү срогы һәм тәртибе

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ автоматлаштырылган мәгълүмати системасыннан гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры белән электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән расписка бирелә.

2.13.2. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетында гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры белән электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

2.13.3. Гариза бирүче Мәгариф идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәү гариза биргән көнне башкарыла.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, муниципаль хезмәттән файдалану турында гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидларның күрсәтелгән объектлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр.

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның

чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

2) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

3) инвалидларның хезмәт күрсәтү урыннарына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү чыганакларын, аларның тормыш эшчәнлеген чикләүне исәпкә алып, тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш белән һәм күреп кабул ителә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-ноктала шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче кертү;

6) йөртүче этне махсус укытуны раслый торган һәм «Йөртүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә тапшырыла торган документы булганда кертергә рөхсәт итү.

Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм әлеге пунктның 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем фадалана алу һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, җирле үзидарәнең башкарма күрсәтмә органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә, гариза бирүче сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату (комплекслы сорату) юлы белән муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлеге йә мөмкин булмавы (шул исәптән тулы күләмдә) турында мәгълүмат алу мөмкинлеге

2.15.1. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкин булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмати стендларда, Мәгариф идарәсенең рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

1) документларны кабул итү һәм карау сроклары үтәлү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;

3) Мәгариф идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) муниципаль хезмәттән файдаланганда гариза бирүченең Мәгариф идарәсе, КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

4.2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу кирәк булган очракта бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең вәкаләтле затлар белән бер хезмәттәшлеге дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

КФҮ аша үзара хезмәттәшлек КФҮ һәм җирле үзидарә органнары арасында тиешле килешү булганда гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары, Бердәм портал, Республика порталы, терминаль җайланмалар ярдәмендә бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталда, Республика порталында яисә КФҮдә алырга мөмкин.

2.15.4. Экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтелми.

Комплекслы соратып алу составында муниципаль хезмәт күрсәтелми.

## 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча бирелгән булса) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Бердәм порталда, Республика порталында Шәхси кабинетны кулланып, гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирергә;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

г) Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) Бердәм порталда, Республика порталында Шәхси кабинетта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат алырга;

е) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Мәгариф идарәсенең, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.2. Гариза бирүчеләрнең кабул итү өчен язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Гариза бирүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш датага һәм вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигында билгеләнгән чикләрдә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала тәмамлана.

Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, гариза бирүче система сората торган мәгълүматларны күрсәтергә тиеш, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләк буенча);

теләгән дата һәм кабул итү вакыты.

Гариза бирүче алдан язылганда хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тапшырган документларга туры килмәве очрагында, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылганда, гариза бирүчегә талон-раслауны чыгартып алу мөмкинлеге тәэмин ителә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны башкарганда, гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан соң 15 минут узгач килмәгән очракта алдан язылуның юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче алдан язылудан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация үтүдән тыш, гариза бирүчедән башка гамәлләр кылуны, кабул итү максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен вакыт интервалының озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.

## III. Административ процедураларның составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм вакыты, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

### 3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдәге гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү;

гариза бирүче тарафыннан бирелгән документлар комплектын кабул итү һәм карау, АИС ЭДСта гаризаны теркәү;

муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү;

муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү (юллама һәм Оешмага кабул итү);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

### 3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

3.2.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе – гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр):

күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

гариза бирүче Мәгариф идарәсенә мөрәҗәгать иткәндә – Мәгариф идарәсе белгече.

3.2.2. Гариза бирүче КФҮгә шәхсән, телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында консультация алырга хокуклы.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны күпфункцияле үзәк сайтыннан http://mfc16.tatarstan.ru ирекле рәвештә алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.2.3. Гариза бирүче Мәгариф идарәсенә телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Мәгариф идарәсе сайтында консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза бирүчегә Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

### 3.3. Гариза бирүче тарафыннан бирелгән документлар комплектын кабул итү һәм карау, АИС ЭДСта гаризаны теркәү.

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү КФҮ яисә КФҮнең читтәге эш урыны аша.

3.3.1.1. Гариза бирүче шәхсән (гариза бирүче вәкиле) муниципаль хезмәте күрсәтү турында сорату белән КФҮгә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмати системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

кәгазь чыганакта Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганда, тапшырылган документларны сканерлый;

КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмати системасыннан гаризаны кәгазьдә чыгартып ала;

гариза бирүчегә тикшерү һәм имза салу өчен тапшыра;

имза салганнан соң, КФҮ автоматлаштырылган мәгълүмати системасында имзаланган гаризаны сканерлый;

КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон образларын урнаштыра, электрон эш формалаштыра;

имза салынган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре гариза бирүчедән кабул ителгән документлар пакетын Мәгариф идарәсенә электрон формада (электрон эшләр пакетлары составында) гариза бирүче КФҮнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән бер эш көне эчендә җибәрә;

- кәгазьдә (документларның төп нөсхәләрен мәҗбүри бирү кирәк булган очракта) – гариза бирүче КФҮнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән алып өч эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Мәгариф идарәсенә җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү өчен, Бердәм портал, Республика порталы аша документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон рәвештә бирү өчен, гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Республика порталында авторизация үтә;

Бердәм порталда, Республика порталында электрон гариза формасын ача;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын раслый (электрон гариза

формасында тиешле билге билгели);

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза) белән имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәр ала.

3.3.2.2. Электрон гариза АИС ЭДСка керә, анда электрон гаризага кертелгән бала турында мәгълүматларның корректлылыгын автоматик рәвештә тикшерү (ЗАГС органнары аша баланы идентификацияләү) башкарыла. Мәгълүматлар корректлы булган очракта, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә.

Әгәр мәгълүматлар корректлы түгел, йә юк икән, гаризага «Документларны раслау» статусы бирелә. Документларны раслау өчен гариза бирүче Мәгариф идарәсенә мөрәҗәгать итә. Документларны Гариза бирүче раслаганнан соң, 1 эш көне дәвамында АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә.

3.3.2.3. Әгәр Гариза бирүче гаризада баланы чираттан тыш, беренче чиратта, өстенлекле итеп Оешмага кабул итү хокукын яисә сәламәтлек буенча ихтыяҗын (компенсацияләүче, катнаш һәм сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәргә керү ихтыяҗы) күрсәтсә, аның гаризасына АИС ЭДСта «Документларны раслау» статусы бирелә. Раслау өчен Гариза бирүче Мәгариф идарәсенә ташламаны, сәламәтлек буенча ихтыяҗны раслый торган документларның төп нөсхәләрен, шулай ук аларның күчермәләрен тапшыра.

Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән ташламалар исемлеге автомат рәвештә әлеге документлар (белешмәләр) алар карамагында булган дәүләт органына яисә оешмага сорату ярдәмендә раслана.

Процедураларның нәтиҗәсе: баланы исәпкә кую – АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирү.

3.3.3. Мәгариф Идарәсе тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү һәм карау.

3.3.3.1. Гариза бирүче шәхсән (гариза бирүче вәкиле) муниципаль хезмәте күрсәтү турында сорату белән Мәгариф идарәсенә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.3.2. Мәгариф идарәсенең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы хезмәткәре:

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан гариза һәм шәхси мәгълүматларны

эшкәртүгә ризалык тутыруны тикшерә(Регламентка2 нче кушымта);

АИС ЭДСта гаризаның электрон формасын тутыра;

кәгазь чыганакта Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганда, тапшырылган документларны күчермәли;

АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирә;

кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баланы исәпкә кую – АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирү.

3.3.4. Мәгариф Идарәсе тарафыннан КФҮ аша кергән документлар комплектын карап тикшерү.

3.3.4.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе булып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килү тора.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) – Мәгариф идарәсе белгече (алга таба – Вәкаләтле хезмәткәр).

Вәкаләтле хезмәткәр, документлар карап тикшерүгә кергәннән соң, түбәндәгеләрне башкара:

а) документларның күчермәләрен һәм документлар реестрын КФҮдән электрон рәвештә (электрон эшләр пакетлары составында) тапшырган очракта документлар реестрын тапшырылган документлар белән тикшерә;

б) кергән электрон эшләрне, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә бирелгән документларны һәм документларның электрон образларын өйрәнә;

в) документларның комплектлылыгын, электрон үрнәкләренең укылышын тикшерә;

г) Гариза бирүченең гаризасыннан мәгълүматларны АИС ЭДСка кертә, АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирә, бу Бердәм порталда, Республика порталында Шәхси кабинетта чагылдырыла.

3.3.4.2. Регламентның 2.7. пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә

Документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләре мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә тәкъдим ителмәгән, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматларның, белешмәләрнең) атамасы турында мәгълүмат булырга тиеш), регламентка № 4 кушымта нигезендә форма буенча рәсмиләштерелә, электрон документлар әйләнеше системасында теркәлә һәм Бердәм порталда, Республика порталында гариза кергән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча КФҮгә һәм гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

3.3.4.3. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.2 пунктларында күрсәтелгән процедураларны

үтәү, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла ала.

3.3.4.4. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза кергән датадан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баланы исәпкә кую – АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирү яки документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

### 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Административ процедураны үтәү өчен нигез – административ процедураны үтәүгә вәкаләтле вазыйфаи затының (хезмәткәрнең) документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) гариза бирүчедән кабул ителгән документларны алуы.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Мәгариф идарәсе боерыгы белән билгеләнгән Мәгариф идарәсе белгече тора, (алга таба – ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

Ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гаризаны теркәгәннән соң, электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булган, норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле белешмәләр бирү турындагы соратуларны формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар карау өчен гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яисә) хакимиятнең ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче белгечләр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документ яисә мәгълүмат бирүче органга яки оешмаларга ведомствоара соратулар кергән көннән алып биш көн эчендә, әгәр ведомствоара соратуга җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) йә, документ һәм (яисә) мәгълүмат

булмаганда, баш тарту турында хәбәрнамә ала.

3.4.3. Әлеге пуектның 3.4.1, 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, шул исәптән Регламентның 2.13 пункты нигезендә гаризаны теркәгән мизгелдән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын файдаланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла ала.

3.4.4. Процедураларның нәтиҗәсе: ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь вакыты биш эш көне тәшкил итә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Оешмага юллама.

3.5.1.1. Административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып АИС ЭДСта гаризаның «Теркәлгән» статусында булуы, теркәлгән чират нигезендә баланы җибәрү өчен Оешмада җитәрлек күләмдә буш урыннар булу тора.

Гариза бирүче чираты якынлашканда һәм теләгән Оешмада тиешле яшь төркемендә урын булган очракта, Вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан баланы АИС ЭДС аша оешмага юллау гамәлгә ашырыла. Гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусы бирелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Системада гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусын бирү.

3.5.1.2. Гариза бирүче «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусын алганнан соң 30 календарь көнгә кадәр баланы кабул итүне раслау өчен Оешмага мөрәҗәгать итә.

Оешма җитәкчесе Гариза бирүче баланы кабул итү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән көннән алып 5 эш көне эчендә АИС ЭДСта гаризага «Шартнамә төзү» статусын бирә.

Баланы кабул итү турында гаризаның тәкъдим ителә торган формасы Регламентка 6 нчы кушымтада тәкъдим ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Шартнамә төзү» статусын бирү.

3.5.1.3. Әгәр Гариза бирүчене бала җибәрелгән Оешма канәгатьләндермәсә, Гариза бирүче тарафыннан әлеге Оешмага җибәрүдән баш тарту рәсмиләштерелә.

Тәкъдим ителгән Оешмага җибәрүдән баш тарту Мәгариф идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә язмача рәсмиләштерелә. Тәкъдим ителгән Оешмага җибәрүдән баш тарту турында гаризаның тәкъдим ителә торган формасы Регламентка 7 нче кушымтада тәкъдим ителә.

АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Шул ук вакытта исәпкә кую датасы үзгәрми. Теләгән кабул итү вакыты Гариза бирүченең җибәрүдән баш тарту турында мөрәҗәгать иткән көненнән дә иртәрәк булмаган датага алыштырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать

иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирү, тәкъдим ителгән Оешмага җибәрүдән баш тарту.

3.5.1.4. Гариза бирүче гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусын биргәннән соң Регламентның 3.5.1.2 пунктында билгеләнгән вакытта Оешмага килмәгән очракта, АИС ЭДСта автомат рәвештә гаризага «Килмәде» статусы бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.1.2 п. белән билгеләнгән вакыт чыкканнан соң 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Килмәде» статусын бирү.

3.5.1.5. Әгәр гариза бирүче үзенең хезмәттән файдалану теләген раслый икән, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Шул ук вакытта исәпкә кую датасы үзгәрми. Әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдаланудан баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды» статусы бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне раслау яки баш тарту Мәгариф идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Мәгариф идарәсе тарафыннан билгеләнгән форма буенча язмача рәсмиләштерелә. Расланганда, теләгән кабул итү вакыты Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗын раслап мөрәҗәгать иткән көненнән дә иртәрәк булмаган датага алыштырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» яисә «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылган» статусын бирү.

3.5.2 Оешмага кабул итү.

3.5.2.1. «Шартнамә төзү» статусы бирелгәннән соң бер ай эчендә Гариза бирүче Оешмага шартнамә төзү өчен мөрәҗәгать итә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) белән шартнамә төзегәннән соң, Оешма җитәкчесе АИС ЭДСта гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителгән» статусын бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ата-аналар (законлы вәкилләр) белән шартнамә төзегәннән соң 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителгән» статусын бирү.

3.5.2.2. Гариза бирүче регламентның 3.5.2.1 пунктында билгеләнгән вакытта шартнамә төзергә килмәгән очракта, Оешма җитәкчесе гаризага «Килмәде» статусын бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар «Шартнамә төзү» статусы бирелгән көннән бер ай вакыт үткәннән соң 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Килмәде» статусын бирү.

3.5.2.3. Әгәр гариза бирүче үзенең хезмәттән файдалану теләген раслый икән, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Шул ук вакытта исәпкә кую датасы үзгәрми. Расланганда, теләгән кабул итү вакыты Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗын раслап мөрәҗәгать иткән көненнән дә иртәрәк булмаган датага алыштырыла.

Әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдаланудан баш тартса, гаризага

«Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды» статусы бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне раслау яки баш тарту яшәү урыны буенча мәгариф идарәсе муниципаль органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Мәгариф идарәсе тарафыннан билгеләнгән форма буенча язмача рәсмиләштерелә.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» яисә «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылган» статусын бирү.

3.5.2.4. Баланы билгеле бер вакытка (вакытлыча, медицина бәяләмәсе яки психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә) компенсацияләүче яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәргән очракта, Вәкаләтле хезмәткәр АИС ЭДСтагы юнәлештә «Вакытлыча кабул итъ»дигән билге куя.

Баланың гаризасы исәпкә куюның беренчел датасы белән чиратта саклана.

Әгәр бала компенсацияләүче яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәрелгән вакытта башка Оешмага йөргән булса, Оешма җитәкчесе, махсуслаштырылган төркемдә булу вакытын күрсәтеп, баланы вакытлыча чыгарып җибәрә.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.6.1. Теркәлгән гаризага шәхси идентификация номеры бирелә. Гариза статусын һәм Оешмага урнашу буенча чиратның торышын Гариза бирүче Бердәм порталда, Республика порталында Шәхси кабинетында баланың туу турында таныклыгы мәгълүматлары (серия һәм номер) яки гаризаның индивидуаль идентификацион номеры буенча, шулай ук Мәгариф идарәсенә шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итеп тикшерә ала.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат дәүләт хезмәтләренең Бердәм порталында, Республика порталында Шәхси кабинетта гариза статусларын алыштыру турында хәбәр рәвешендә күрсәтелә («Теркәлгән», «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән», «Шартнамә төзү», «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителгән», «Килмәгән»).

Процедураны үтәү, АИС ЭДС кулланып, автомат режимда башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү.

3.7. Оешмада тәрбияләнүченең ата-аналары (законлы вәкилләре) үз инициативасы белән Оешма (алга таба әлеге пунктта – башлангыч оешма) тәрбияләнүчесе булган баланы, дәүләт, муниципаль (шул исәптән башка Оешмага) яисә мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган шәхси белем бирү оешмасына (алга таба әлеге пунктта – кабул итүче оешма) күчерергә хокуклы.

Оешмадан башка Оешмага күчергәндә ата-аналар (законлы вәкилләр):

- башка Оешмага җибәрү өчен Идарәгә мөрәҗәгать итәләр;

Башка Оешмада урын бирү турында мәгълүмат алганнан соң, кабул итүче оешмага күчерелүгә бәйле рәвештә, тәрбияләнүчене чыгару турындагы гариза белән башлангыч Оешмага мөрәҗәгать итәләр.

Оешмадан күчергәндә башка очракларда ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) эш тәртибе Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм (булган очракта) җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.

Тәрбияләнүченең ата-анасының (законлы вәкилләренең) күчерү тәртибендә чыгару турында гаризасы нигезендә башлангыч оешма өч көн эчендә, кабул итүче оешманы күрсәтеп, укучыны күчерү тәртибендә чыгару турында күрсәтмә акты төзи.

Башлангыч оешма ата-аналарга (законлы вәкилләргә) тәрбияләнүченең анда булган документларының исемлеге белән шәхси эшен (алга таба – шәхси эш) бирә. Ата-ана (законлы вәкил) шәхси имзасы белән анда булган документларның исемлеге белән шәхси эшне алуын раслый.

Башлангыч оешмадан күчерү белән бәйле рәвештә баланы кабул итүче оешмага кабул итү өчен нигез сыйфатында башка документлар бирүне таләп итү рөхсәт ителми.

Шәхси эш укучыны күрсәтелгән оешмага башлангыч оешмадан күчерү тәртибендә күчерү турындагы гариза белән бергә һәм, укучының ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен раслый торган документның төп нөсхәсен күрсәткәч, кабул итүче оешмага укучының ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан тапшырыла.

Регламент нигезендә кабул итү өчен кирәкле документлар күчермәләре шәхси эштә булмаган очракта, кабул итүче оешма булып торучы Оешма мондый документларны ата-анадан (законлы вәкилдән) соратып алырга хокуклы.

Баланы бер Оешмадан икенчесенә мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми белем программасы буенча укырга җибәрү өчен, бер Оешмадан икенчесенә мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми белем бирү программасы буенча укуга күчүгә бәйле рәвештә баланы чыгару турында гариза һәм баланы мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми белем бирү программасы буенча укуга күчерү тәртибендә бер Оешмадан икенчесенә кабул итү турында тәкъдим ителә торган гариза формалары Регламентка 8 – 10 нчы кушымталарда тәкъдим ителгән.

АИС ЭДСка күчерү өчен гаризадагы мәгълүматларны керткәндә, ата-аналар тарафыннан тиешле гариза бирү датасы куела. Баланы бер Оешмадан икенчесенә күчергәндә ташламалы категориядәге гражданнарның балалары федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм законлы норматив хокукый актларда билгеләнгән ташламалардан файдалана.

3.8. Гражданнар гаризалары буенча (кызыксынган ике яктан да) бер яшь категориясендәге төркемнәргә йөрүче бер яшьтәге балалар арасында ике төрле Оешмада урыннар белән алмашырга рөхсәт ителә. Алмашу өчен гаризалар Идарәгә тапшырыла.

Идарә урыннарны алмаштыру өчен кергән гаризаны Гариза бирүчеләр гариза нигезендә үз балалары арасында урыннарны алмашырга теләгән Оешмаларга җибәрә.

Оешма Идарәдән урыннарны алмаштыру өчен гаризаны алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча балигъ булмаган затның тиешле ата-анасына (законлы вәкиленә) урын бирү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән хәбәр алынган көннән алып бер ай эчендә балигъ булмаган затның ата-анасы (законлы вәкиле) баланы кабул итү турында гариза белән тиешле Оешмага мөрәҗәгать итә.

Бер яшь категориясенә йөрүче бер яшьтәге балалар арасында төрле ике Оешмада урыннар алмашу турында гаризаларның тәкъдим ителә торган формасы Регламентка 9 нчы кушымтада күрсәтелгән.

3.9. Оешма эшчәнлеген бетерү яки туктатып тору турында Карар кабул иткәндә, тиешле боерык актында тәрбияләнүчеләр әти-әниләренең (законлы вәкилләренең) язма ризалыгы нигезендә күчереләчәк кабул итүче Оешма яисә кабул итүче Оешмалар исемлеге күрсәтелә.

3.10. Техник хаталарны төзәтү

3.10.1. Гаризага шәхси идентификация номеры бирелгәннән соң, муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, Идарәгә (әгәр техник хата Идарә биргән документта табылса) яисә Оешмага (әгәр техник хата Оешма биргән документта табылса), хатаның булуын раслый торган документларны кушып, техник хаталарны төзәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаның тәкъдим ителә торган формасы регламентка 12 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.10.2. Вәкаләтле хезмәткәр, муниципаль хезмәт алуга гариза биргән көннән алып 5 эш көне эчендә, җибәрелгән хаталарны (баланың Ф.И.А., туу датасы, туу турында таныклык реквизитларында һ. б., исәпкә кую датасыннан тыш) бетерү максатларында, гражданның АИС ЭДСтагы гаризасына кирәкле төзәтмәләр кертергә хокуклы. Бирелгән вакыт узганнан соң үзгәрешләр кертү вәкаләтле хезмәткәр гаризасы буенча АИС ЭДС администраторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яисә җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алганнан соң ике эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: АИС ЭДСтагы гаризада хаталарны төзәтү.

3.10.3. Гаризага индивидуаль идентификацион номер бирелгәннән соң, Гариза бирүче гаризасы буенча заявкада теләгән Оешманы алыштыру рөхсәт ителә. Гариза бирүче теләгән Оешманың урнашу урыны буенча мәгариф белән идарә итүнең муниципаль органнарына теләгән Оешманы алмаштыруга гариза бирә. Исәпкә кую датасы шул ук вакытта саклана.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура теләгән Оешманы алмаштыруга гариза алганнан соң, 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче теләгән Оешманы Бердәм портада, Республика порталында Шәхси кабинетында гаризада үзгәртә ала.

Процедураның нәтиҗәсе: АИС ЭДСтагы гаризада теләгән Оешманы алыштыру.

3.11. Гариза бирүчегә Идарәгә (Оешмага) килү кирәклеге турында һәм (яисә) Идарәгә (Оешмага) документларның төп нөсхәләрен (күчермәләрен) тапшыру кирәклеге турында хәбәр ителгән дип санала, әгәр түбәндәге ысулларның берсен генә кулланып булса да мәгълүмат бирү чарасы күрелсә:

- Бердәм порталда һәм (яисә) Республика порталында Гариза бирүченең шәхси кабинетында тиешле мәгълүматны урнаштыру;

- телефон аша хәбәр итү;

- кәрәзле телефон ярдәмендә текстлы хәбәр (СМС-хәбәр) ;

- мессенджер ярдәмендә хәбәр итү;

- электрон почта адресына хәбәр (мәгълүмат) юллау юлы белән хәбәр итү;

- заказлы хат җибәрү юлы белән мәгълүмат бирү;

- хәбәрнамәнең (мәгълүматның) теркәлүен һәм аның Гариза бирүчегә җибәрелүен тәэмин итә торган башка элемтә һәм илтеп тапшыру чараларыннан файдаланып, мәгълүмат җиткерү;

- телдән яисә язма рәвештә турыдан-туры хәбәр итү (мондый хәбәрне язмача теркәп).

Хәбәр итү өчен Идарә (Оешма) Гариза бирүче гаризада, муниципаль хезмәт күрсәтү барышында Гариза бирүчедән кергән башка документларда күрсәткән мәгълүматлардан файдалана.

Идарә (Оешма) тарафыннан югарыда күрсәтелгән хәбәр бирү чаралары кабул ителгән очракта, Гариза бирүчеләрнең мәгълүмат алу буенча чаралар күрмәүләре уңайсыз нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Гариза бирүчеләргә, гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргән очракта, бу хакта Идарәгә (Оешмага) вакытында хәбәр итәргә, Бердәм порталда һәм Республика порталында шәхси кабинетларында яңа (актуаль) мәгълүмат булуын (булмавын) даими күзәтеп торырга тәкъдим ителә.

## IV. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм башкарылуын агымдагы контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклауны һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документларның проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) эш башкаруны алып бару буенча билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган белешмәләр, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка белешмәләр файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә җирле үзидарә органы җитәкчесенә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар муниципаль хезмәт күрсәтүче

орган җитәкчесенә кичекмәстән хәбәр итәләр, шулай ук хокук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм чоры, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм формалары

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затларының муниципаль хезмәт күрсәтү барышында алар кабул итә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе белдерүләрне вакытында тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (башкарыла) торган карарлар һәм кылына (кылынмый) торган гамәлләр өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә таләпләрне характерлаучы нигезләмәләр, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да

Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшереп тору муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

**5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның**

**вазыйфаи затларының, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Идарә һәм Оешмалар хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең үтенечен теркәү вакытын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны бирүне яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу;

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта, аны туктатып тору;

10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәткәндә аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь чыганакта, электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы) тапшырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә йә, ул булмаган очракта, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче

орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәкнең хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга бирелә. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Мәгариф идарәсенең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталыннан, судка кадәр шикаять бирүнең мәгълүмат системасыннан файдаланып, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмаларның исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр яки гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номер(-лар)ы, гариза бирүчегә җавап юлланырга тиешле электрон почта адрес(-лар)ы (булган очракта) һәм почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның вазыйфаи затының йә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) гариза бирүченең хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен күрсәтүче дәлилләр.

5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять ул кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә һәм аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның Гариза бирүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартулары турында яисә билгеләнгән срокларны бозган өчен шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган

документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән түләү алу каралмаган очракларда алынган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, Башкарма комитет, күп функцияле үзәк яисә 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга кирәк булган алдагы гамәлләре турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмалары турында мәгълүматлар

| Оешманың атамасы | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) җитәкченең (мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен), мәктәпкәчә белем бирү буенча җитәкче урынбасарының (калган белем бирү оешмалары өчен) | Оешманың адресы/сайты | Телефон | Оешманың Эш режимы Җитәкченең кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 1 номерлы «Каенкай» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Владимирова Людмила Александровна | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Вахитов ур., 7 йорт | 8(84364) 29488 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 2 номерлы «Чулпан» катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Идиятуллина Ландыш Хәнәфи кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Нур Баян ур., 44 йорт | 8(84364) 29077 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 3 номерлы «Кояшкай» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Аксанова Альбина Равил кызы | 422110, Татарстан республикасы, Кукмара ш., Гафиятуллин ур., 20 йорт | 8(84364) 40106 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 4 номерлы «Лэйсән» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Мөхәммәдиева Энҗе Мәсхүт кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Планетарий ур., 2 йорт | 8(84364) 26143 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 5 номерлы «Йолдызлык» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Зиннәтуллина Зөһрә Хәлил кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Гафиятуллин ур., 22 йорт | 8(84364) 40131 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 6 номерлы «Салават | Каюмова Лилия Иосиф кызы | 422110, Татарстан Республикасы, | 8(84364) 27081 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; |

| Оешманың атамасы | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) житәкченең (мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен), мәктәпкәчә белем бирү буенча җитәкче урынбасарының (калган белем бирү оешмалары өчен) | Оешманың адресы/сайты | Телефон | Оешманың Эш режимы Җитәкченең кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| күпере» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | | Кукмара ш., Эшчеләр тыкрыгы ур., 4а йорты | | 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 7 номерлы «Кыңгырау» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Гобәйдуллина Рузалия Әһлиулла кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ленин ур., 77 йорт | 8(84364) 27148 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 8 номерлы «Гөрләвек» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Гайнетдинова Зөлфия Зөфәр кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ворошилов ур., 19 йорт | 8(84364) 26150 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 9 номерлы «Миләшкәй» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Шәйхиева Энҗе Аманулла кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ст. Разин ур., 89 йорт | 8(84364) 26373 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре 10 номерлы «Ромашка» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Зыятдинова Гөлназ Ринат кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Тимер юл ур., 17 йорт | 8(84364) 29302 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Әсән-Елга авылы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Гарифянова Римма Васыйл кызы | 422130, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Әсән-Елга авылы, Яшьләр ур., 3 йорт | 8(84364) 34234 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Иске Юмья авылы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Антонова Лариса Геннадьевна | 422102, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Иске Юмья авылы, Үзәк ур., 69а йорты | 8(84364) 32702 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Үрәсбаш авылы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү | Павлова Любовь Николаевна | 422132, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Үрәсбаш авылы, | 8(84364) 37136 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә |

| Оешманың атамасы | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) җитәкченең (мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен), мәктәпкәчә белем бирү буенча җитәкче урынбасарының (калган белем бирү оешмалары өчен) | Оешманың адресы/сайты | Телефон | Оешманың Эш режимы Җитәкченең кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| учреждениесе | | Пионер ур., 19 йорт | | кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Манзарас авылының 1 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Мөхәммәтова Миләүшә Фоат кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Манзарас авылы, 1 Май ур., 40а йорты | 8(84364) 29604 | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Киндеркүл авылы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Сабирова Гөлнара Каюм кызы | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Аш-Бужи авылы, Клуб ур., 4 йорт | | Биш көнлек, ял көннәре – шимбә-якшәмбе; 7.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр; төшке ялсыз. |
